**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительного комитета Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**« 01 » август 2019 ел** **№ 244**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 03.04.2019 ел №85 «Төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчалары) балаларны исәпкә кую һәм күчерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты турында» карарына үзгәрешләр кертү турында (22.05.2019 ел №118 карар редакциясендә)

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның өстәмә гарантияләрен билгеләү өлешендә» «Федераль законга үзгәрешләр турында» 19.07.2018 ел 204-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты карар чыгара:

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 03.04.2019 ел №85 «Төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчалары) балаларны исәпкә кую һәм күчерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты турында» карарына (22.05.2019 ел №118 карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктның 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- һәлак булган (хәбәрсез югалган), инвалид булган хезмәткәрләрнең һәм Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ регионы территориясендә террорчылык акцияләрен оештыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашучы террорчылык оешмалары һәм төркемнәренең, аларның лидерларының һәм затларның эшчәнлеген ачыклау һәм булдырмау буенча махсус көчләр хәрбиләренең, шулай ук Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ регионы территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр үткәрү буенча берләштерелгән гаскәрләр (көчләр) төркеме хезмәткәрләренең һәм хәрбиләренең балалары»;

1.2. 1.2 пунктның 13 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«-махсус исемнәре һәм җинаять-башкарма системасы оешмаларында һәм органнарында хезмәт итүче, янгынга каршы дәүләт хезмәтенең Федераль янгынга каршы хезмәтендә һәм Россия Федерациясе таможня органнарында хезмәт итүче хезмәткәрләрнең балалары, Россия Федерациясенең таможня органнарында һәм учреждениеләрендә, янгынга каршы дәүләт хезмәтенең Федераль янгынга каршы хезмәтендә хезмәт итүдән азат ителгәннәр балалары һәм аларның гаилә әгъзалары

һәм алар тәрбиясендә булган затларга, аларга башка социаль гарантияләр бирү беләнә.».

1.3. 2.8 пунктының 2 пунктчасына түбәндәге редакциядә 3 абзац өстәргә:

«- «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 ел 273-ФЗ номерлы Федераль законның 67 статьясындагы 5 һәм 6 өлешләрендә һәм 88 статьясында каралган очраклардан тыш, муниципаль белем бирү оешмасына кабул итүдән бары тик анда буш урыннар булмау сәбәпле генә баш тартылырга мөмкин. Муниципаль белем бирү оешмасында урын булмаган очракта, баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) аны башка гомуми белем бирү оешмасына урнаштыру мәсьәләсен хәл итү өчен «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе»муниципаль учреждениясенә мөрәҗәгать итә.

1.4. 2.5 пунктның 5 пунктчасындагы 5 абзацта «бала» сүзеннән соң «сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, инвалид бала» сүзләрен өстәргә.

1.5. 4.2 пунктта «Палата рәисе» сүзләрен «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ начальнигы сүзләренә алмаштырырга.

1.6. 4.2 пунктта «Палата белгечләре» сүзләрен Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе белгече» сүзләренә алмаштырырга.

1.7. 4.5 пунктта «Палата» сүзләрен «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» сүзләренә алмаштырырга.

1.8. 5.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шикаятьне карау барышында яисә карау нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре билгеләнгән яки җинаять кылган очракта, 5.2 пунктның 5 өлеше нигезендә шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат. булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрәләр.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» : http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет - телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.Р.Гыйләҗевка йөкләргә.

Җитәкче А.Х.Шәмсетдинов